КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 20 гыйнвар г.Казань № б-58

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын – 2021 елга 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның гомуми файдаланудагы хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре чикләрендә урнашкан су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларын җыю һәм алып китү мәйданчыкларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен үткәрү өчен 150 000,0 мең сум финанслау күләмендәге акча белән баш эш итүче итеп, шулардан түбәндәге эшләрне үткәрүгә;

2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның гомуми файдаланудагы хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләре чикләрендә урнашкан су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү буенча – 140 000,0 мең сум;

2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның каты коммуналь калдыкларын җыю һәм алып китү мәйданчыкларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү буенча – 10 000,0 мең сум;

«Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен – 2021 елга 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның гомуми файдаланудагы хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре чикләрендә

урнашкан су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларын җыю һәм алып китү мәйданчыкларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен үткәрүнең дәүләт заказчысы итеп;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын – 2021 елга 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның чикләренә кадәр килә торган юлларны капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен үткәрү өчен 300 000,0 мең сум финанслау күләмендәге акча белән баш эш итүче итеп;

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен – 2021 елга 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренең, шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның чикләренә кадәр килә торган юлларны капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү буенча дәүләт заказчысы итеп;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын – 2021 елга 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләре, шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар территориясендә электр челтәре хуҗалыгы объектларын (1 000 В га кадәр электр челтәрләрен кертеп) төзү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен үткәрү өчен 100 000,0 мең сум финанслау күләмендәге акча белән баш эш итүче итеп.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына 2021 елның 1 маена кадәр 2019 елның 1 гыйнварына кадәр бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән инфраструктурасын модернизацияләүне таләп итә торган бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләре, шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин